Интернетта хәзер халык -
Килде шундый замана.
Инстаграм,тик- ток,контакт,
Барсы шунда казына.

Бар да телефон сыпыра,
Әбисе дә , кызы да
Карамыйбыз, кирәк түгел
Хәтта  телевизор да.

Кырык эшең тора читтә,
Кузгалып булмый һич тә.
Куйган ашлар ташый газда.
Пироглар көя мичтә.

Кунакларга йөрешмибез,
Күрше керми күршегә.
Ватсап аша сөйләшәбез,
Вакыт юк күрешергә.

Интернетта эти – әни.
Абый,бабай ,әбиләр.
Ә үзләре ни өчендер
һаман безне әрлиләр.

Ни генә дип әйтсәләр дә,
Аннан башка булмый һич.
Электрон көндәлекләр,
Өй эшләре шунда ич

Ярамый дип торып булмый
Шуна булгач тормышың
Белмәгән әйберләр булса
"Алиса"дан сорыйсың

Ул кыз бигрәк кызык икән
Бөтен нәрсәне белә
Теләгән һәммә нәрсәне
Ялт итеп әйтеп бирә

Төне буе утырасың
йокы да килми алай...
Нигәдер тамак та ачмый
Ашыйсы да юк,малай!

Кием салым кирәк булса
Заказ бирәсең өйдән
Кибеткә дә барасы юк

Өеңә килә,тиздән

Тәмлүшкә пешерәм дисәң
Язасың да сорыйсың
Пешекче өйрәтеп тора
Артыннан кабатлыйсың

Бу интернет дигәннәре
Барысын да булдыра
Кайбер ачык авызларны
Йортсыз,җирсез калыра

Файдасы күп,зыянында
Аңларга иде дә бит...
Шулай дуслар!Җырлата да
Елата да интернет!